**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**2022 елның 20 июне** **33 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында "гы 28 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Александр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында "гы 28 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге башлыгы Ю.Г.Трифоновага йөкләргә.

Башлык-Татарстан Республикас
Лаеш муниципаль районы
Александр авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.Г.Трифонова

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Александр авыл җирлеге Советының
2022 елның 20 июнендәге 33 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Александр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмә

**1) 1.6 пунктын түбәндәге пункт белән тулыландырырга:**

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре, инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

**2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

Әлеге статьяда каралган гражданнарның җыены, торак пунктта яисә җирлектә яшәүче сайлау хокукына ия булучыларның яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия халыкның яртысыннан күбрәге бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, халык җыены, әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә, этаплап, җыен үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.";

**3) 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча».